СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 20 » апрель 2021 ел** **№ 55**

**Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру буенча комиссия турында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмә нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. Расларга:

Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында Нигезләмәне (1 нче кушымта).

Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составын (2 нче кушымта).

2. «Арча муниципаль районында вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында» Арча район Советының 2014 елның 05 апрелендәге 257 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясен йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

.Арча район Советының
"20" апрель 2021 ел, № 55
карарына 1 нче кушымта

**Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы вазыйфалар биләүгә кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында**
**Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә белән Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) эшчәнлеге тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия даими эшләүче орган булып тора һәм үз эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Арча муниципаль районы Уставы, башка муниципаль хокукый актлар, Арча муниципаль районында югары һәм баш вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру буенча төзелгән килешүләр, Арча муниципаль районында, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Комиссиянең составы Арча муниципаль районы Советы тарафыннан төзелә һәм раслана.

## II. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре

4. Комиссиянең төп бурычлары:

1) Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар резервын формалаштыруны һәм алардан нәтиҗәле файдалануны оештыру;

2) Арча муниципаль районының, район составына керүче җирлекләрнең кадрлар резервын формалаштыру эшчәнлеген координацияләү.

5. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

1) Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турындагы Нигезләмә (алга таба - кадрлар резервы турындагы Нигезләмә) нигезендә кадрлар резервына кертү өчен дәгъвачыларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү;

2) һәр дәгъвачыны баллы бәяләү системасына нигезләнгән конкурс нигезендә сайлап алу методикасын раслау;

3) Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, район составына керүче җирлекләрнең ел саен вакантлы вазыйфаларны биләү өчен дәгъва

кылучыларга ихтыяҗын бәяләү.

## III. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

6. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, район составына керүче җирлекләрдән Комиссия эшчәнлеген башкару өчен кирәкле мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

2) үз утырышларында граждан дәгъва кылган вазыйфа буенча эшчәнлек өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча экспертларның фикерен тыңларга;

3) гражданнарга тест үткәрүне оештырырга һәм аларның һәркайсына психологик портрет төзү өчен дәүләт мәгариф учреждениеләре белән килешү төзергә.

7. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен комиссия түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) Арча муниципаль районы, район составына керүче җирлекләр гражданнарына һәм җирле үзидарә органнарына кадрлар резервына кертү, конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре, конкурс нигезендә сайлап алу үткәрү һәм гражданнарны кадрлар резервыннан төшереп калдыру турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә;

2) кадрлар резервына дәгъвачыларның башлангыч исемлеген кертү максатыннан Арча муниципаль районының, район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган документларны һәм материалларны карарга һәм эксперт бәяләмәсе үткәрергә;

3) дәгъва кылучыдан үзе тәкъдим иткән анкетада күрсәтелгән персональ белешмәләрдән файдалануга язма ризалык алырга;

4) конкурс сайлавының беренче этабын уздыру йомгаклары буенча кадрлар резервы турындагы Нигезләмәдә каралган карарларның берсен кабул итәргә һәм аның турында язмача рәвештә дәгъвачыларга һәм җирле үзидарәнең тиешле органнарына конкурс нигезендә сайлап алуның икенче этабын үткәрүгә кадәр 5 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;

5) сайлап алуның икенче этабында һәр дәгъвачының нәтиҗә баллын билгеләп, дәгъвачыларны бәяләүне үткәрергә;

6) конкурс сайлавының икенче этабында катнашучы дәгъвачыларны кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә;

7) кадрлар резервына кертелгән гражданнарны әзерләү буенча гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашырырга;

8) кадрлар резервына кертелгән гражданнарны әзерләүнең хосусый планнарын үтәү турында Арча муниципаль районы, район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан ел саен тапшырыла торган хисапларны гомумиләштерергә һәм анализларга;

9) кадрлар резервы турындагы Нигезләмәдә каралган очракларда, гражданны кадрлар резервыннан чыгару турында карар кабул итәргә;

10) Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләү өчен кадрлар

резервына кертелгән гражданнар Исемлеген урнаштыруны тәэмин итәргә.

## IV. Комиссиянең эш тәртибе

8. Комиссия утырышлары Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, район составына керүче җирлекләрнең вакантлы вазыйфаларны биләү өчен дәгъвачы булу ихтималын ел саен билгели торган Комиссиянең эш планы нигезендә уздырыла. Кирәк була калса, Комиссиянең чираттан тыш утырышлары уздырыла ала.

9. Комиссия Комиссия рәисе, секретаре һәм Комиссия әгъзаларыннан (алга таба - комиссия әгъзалары) тора.

10. Комиссия рәисе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

2) Комиссиянең эш планын раслый, Комиссиянең чираттан тыш утырышын чакыру турында карар кабул итә;

3) Комиссия утырышларын үткәрү урынын һәм вакытын билгели;

4) Комиссия утырышларында рәислек итә;

5) Комиссия карарларына, утырыш беркетмәләренә, хатларга имза сала;

6) үз компетенциясе чикләрендә Комиссия кабул иткән карарларның үтәлешен тикшереп тора.

11. Комиссия секретаре түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Комиссиянең эш планнарын әзерли;

2) Комиссия утырышын уздыру урыны һәм вакыты турында Комиссия әгъзаларына хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

3) Комиссиягә керә торган документларны һәм материалларны кабул итә, аларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә, аларны Комиссия утырышында карау өчен әзерли;

4) Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

5) конкурс нигезендә сайлап алуның икенче этабында дәгъвачылар тарафыннан җыелган балларны санауны гамәлгә ашыра;

6) Комиссиянең утырышлар беркетмәләрен, хатларны һәм Комиссия карарын рәсмиләштерә.

12. Комиссиянең башка әгъзалары түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар:

1) Комиссия утырышларында, карарлар проектларын әзерләүдә катнашалар;

2) Комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;

3) Комиссия рәисе йөкләмәләрен үтиләр;

4) тиешле белешмә-мәгълүмат материаллары белән танышалар.

Комиссия әгъзалары саны 7 кеше тәшкил итә.

14. Комиссия утырышы, әгәр анда аның барлык әгъзалар катнашса, хокуклы дип санала.

15. Комиссия карарлары Комиссия әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы

хәлиткеч була.

16. Тавыш бирү нәтиҗәләре һәм конкурс сайлавы дәгъвачыларының һәркайсының нәтиҗә баллары утырыш беркетмәсендә теркәлә һәм Комиссия карары белән рәсмиләштерелә.

17. Комиссия утырышы карары һәм беркетмәсе аның рәисе тарафыннан имзалана.

18. Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү, утырышлар беркетмәләрен һәм Комиссия карарларын саклау буенча оештыру-техник эшне башкару бурычлары Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының кадрлар секторына йөкләнә.

19. Комиссия әгъзалары аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша.

Арча район Советының
"20" апрель 2021 ел, № 55
карарына 2 нче кушымта

**Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Мөхәмәтова Алсу Фирдәүсовна | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, Арча район Советы рәисе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Салихова Эльвина Илфатовна | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының кадрлар секторы мөдире, комиссия секретаре; |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Батталова Резеда Хатыйповна | - Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башлыгы; |
| Галимуллин Радик Наилевич | - Арча район Советы аппараты җитәкчесе; |
| Митина Ольга Геннадиевна | - Арча район Советы аппаратының юридик мәсьәләләр буенча бүлеге баш белгече; |
| Галимова Светлина Петровна | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесе; |
| Гапдерахманова Гүзәл Әдһәмовна | - Арча район Советы аппаратының гомуми-оештыру бүлеге җитәкчесе. |